**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 17 апрель № 258

г. Казань

«Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы исемен үзгәртү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы исемен «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (алга таба – фонд) итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Фонд эшчәнлегенең төп максаты итеп Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерүгә булышлык күрсәтү дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына 30 көн эчендә «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставына тиешле үзгәрешләр кертергә һәм аларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\258.doc